РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ТИМЕРШИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422057, Республика Татарстан,
Сабинский район,
с.Тимершик, ул. Пионерская, 19а
тел. (84362)2-23-23

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТИМЕРШЫК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422057, Татарстан Республикасы,
Саба районы, Тимершык авылы,
Пионер урамы, 19а
тел. (84362)2-23-23

e-mail: Timer.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
03.04.2026

КАРАР
№12

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Тимершык авыл
җирлеге Советының 12.11.2025 №11
карары белән расланган Татарстан
Республикасы Саба муниципаль районы
Тимершык авыл җирлеге территориясендә
төзекләндерү өлкәсендә муниципаль
контроль турындагы Нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Төзелеш Министрлыгының «Дәүләт торак күзәтчелеген һәм муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычының типовой индикаторларын раслау турында» 2025 елның 20 маендагы 301/пр номерлы боерыгы, РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 30 сентябрендәге 1670 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» 2025 елның 12 ноябрендәге 1783 номерлы карары нигезендә, Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында» 12.11.2025 №11 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.9 һәм 1.10 пунктлар өстәргә:

«1.9 Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда Администрация, шулай ук контроль чаралар уздыруга җәлеп ителә торган белгечләр, экспертлар тарафыннан рәсмиләштерелә торган документлар электрон документ рәвешендә төзеләләр һәм көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланалар.

1.10. Профилактик визит уткәрү турында, кисәтү игълан итү турында, контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тота торган контроль

чараны үткәрү турында карарлар, контроль чараның, профилактик чараның актлары (шул исәптән уздыру мөмкинлеге булмау турындагы актлар), ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләр контроль чараларның бердәм реестрына алар турында белешмәләр (күзәтчелек) чаралары һәм аларга имза салу кертү юлы белән рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән карарларны, актларны һәм күрсәтмәләрне рәсмиләштерү өчен документны аерым төзү таләп ителми.»;

1.2. 2.4. нче пунктка түбәндәге эчтәлекле икенче җөмлә өстәргә:

«Контроль объекты контроль төрләренең бердәм реестрына белешмәләр кертелгәннән соң хәвеф-хәтәр категорияләренең берсенә кертелгән дип санала.»;

1.3. 3.8. нче пунктның дүртенче абзацындагы беренче җөмләдә «әлеге кисәтүгә карата» сүзләреннән соң «,шул исәптән бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә регион аша» сүзләре өстәргә;

1.4. 3.9. пунктның беренче абзацында «видео-конференц-элемтә,» сүзеннән соң «Инспектор» мобиль кушымтадан файдалану» сүзләрен өстәргә,»;

1.5. 4 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 4.24 пункт белән тулыландырырга:

«4.24. Документлар буенча тикшерелгәндә документлар контрольдә тотылучы затлар тарафыннан бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан яисә «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып тапшырылырга мөмкин»;

1.6. 4.1 пунктының 6) пунктчасын «карау,» сүзләреннән соң «, шул исәптән пилотсыз аппаратлар (системалар) кулланып» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/timershik адресы буенча рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Тимершык авыл
җирлеге Башлыгы А.Х. Хаҗиев